ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ДЕКАБРЬ, 2017нче ел

№4 (34)

## ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!






**1— коррупциягә каршы көрәш көне.**

**2 - Халыкара инвалидлар көне**

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Шәфкатьлелек бизи кешене | 2 |
| Якыннан танышыйк | 3 |
| Олимпиада–сәләтлеләр бәйгесе | 4 |
| Хуш киләсең, Яңа ел! | 5 |
| Укучылар иҗаты | 6 |
| Шигриятьтә беренче адымнар | 6 |
| Котлыйбыз! | 7 |


## Дәрәҗәне сатып алган кеше аннан табыш алуны гадәткә кертә

Коррупция-ришвәт алу яки бирү юлы белән теләгеңә ирешү. Дәүләтчелек булган җирдә коррупция булмый кала алмый. Чөнки һәр дәүләттә чиновниклар бар. Ә коррупция – ул чиновниклар чире. Аны дәвалау бик авырдыр , күрәсең. Дәүләтләр бу чир белән күп гасырлар буе көрәшкән. Ләкин нәтиҗәсе генә бик күренми. Шулай да кайбер дәүләтләр уңышка ирешкән дияргә мөмкин. Тик безнең дәүләт түгел.Киресенчә,ришвәтчелек(коррупция) бездә киңрәк колач ала бара. Элек урта мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлаган егет-кызлар югары уку йортларына үз көчләре белән кергәннәр, уңышлы гына укып чыгып, теләгән белгечлеген алып, кешеләргә, илгә намуслы хезмәт иткәннәр. Хәзер исә күп акчалы кешеләрнең балалары, ришвәт биреп, дипломлы булалар. Андый белгечтән кешегә нинди файда?! Ришвәт бирү юлы белән укып чыккан табиб, укытучы, юрист кебек имгәкләр кешеләргә нинди ярдәм күрсәтә алсын? Юк, билгеле. Шуңа күрәдер бәлки, соңгы вакытта табиблар гаебе белән үлүчеләр күбәеп китте; төзелгән йортлар, күперләр җимерелә; нинди дер тузга язмаган реформалар үткәрелә.Нинди генә белгеч булса да, әгәр ул ришвәт биреп укып чыккан икән, аннан нәтиҗәле эш көтеп булмый. Ә андыйлар саны ишәйгәннән ишәя бара. Коррупция юлы белән кулга төшерелгән диплом ияләренең намуслы хезмәт итүләренә дә ышанасы килми. Тагы да югарырак урләр өчен, җайлырак, “җылырак” урын биләр өчен акча төртмәсләр, ришвәт бирмәсләр дип кем әйтә ала! Ә бирүче булганда алучы һәрвакыт табыла.Димәк, алучылар белән генә түгел, бирүчеләр белән дә көрәшергә кирәк. Көрәш аяусыз булырга тиеш. Законнар әйләнеп үтешле булмаса, җәза каты булса, бәлки нәрсәгә дә булса ирешә алырбыз. Ләкин кеше факторы барыбер алгы планда кала.Балаларны алдашмыйча, урлашмыйча, намус белән яшәргә өйрәтү һәр ата-ананың бурычы булырга тиеш. Коррупциягә каршы көрәшне һәркем үзеннән башласа



# Шәфкатьлелек бизи кешене.

*Халкыбызда әүвәл-әүвәлдән ятимнәргә, кулы-аягы гариплэргә, язмыш кимсеткән, табигать кыерсыткан кешеләргә аерым бер гадәт яшәп килгән. Аларны кызганганнар, хәлләренә кергәннәр, кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышканнар. Аларга карап: «Биргәненә шөкер, акылым тулы, зиһенем бөтен",-дигәннәр, гыйбрәт алганнар, тәүбә иткәннәр. Мондый кешеләргә карата шәфкатьле булганнар.*

*Бүгенге авыр заманда шәфкатьле булу бигрәк тә кирәк.Ана назын, ата сөюен күрмәгән күпме ятим бар. Инвалидлар, картлар йортлары күбәюе дә безгә, яшь буынга, шул турыда чаң суга. Шәфкатьле булу — барлык күркәм гадәтләрнең башы, әдәплелекнең нигезе дип әйтсәм, минем белән килешерсез дип уйлыйм. Чөнки бары тик шәфкатьле бала гына күркәм гадәтләргә ия, бәхетле, тәүфыйклы, мәрхәмәтле, кешелекле була ала.*

*Безнең Фома авылында да бар андый кешеләр. Ул—Галимова Нурия апа. Үзе тумыштан ишетми, шуңа карамастан,*

*төшенкелеккә бирелмичә, тормышта үз юлын табып, күтәренке күңел белән кешеләргә ярдәм кулы сузып , дөньяның ямен—тәмен татып яши. Тормышы да исән кешеләрнекеннән бер дә ким түгел. Газы, суы кергән. Тормыш өчен кирәк булган бар көнкүреш җиһазлары җитеш. Гомеренең күп өлешен энисе белән яшәгәнгәдер инде, ул аннан үзенә кирәкле булган һөнәрләргә өйрәнә: тегә, эрли, бәйли. Гозер белән килүче авыл халкына ни сорасалар, шуны тегеп бирә, кирәк дип тапсалар бәйләп тә кинәндерә Нурия апа. Олы йөрәкле, саф күңелле, кеше яратучан, бик уңган кешелекле кеше ул. Авыл халкы аны хөрмәт итә. Кулларыннан килгәнчә ярдәм итеп торалар. Үзен генә калдырмыйлар, хәлен беләләр. Мәктәп коллективы һәм дә укучылар да һәрдаим аның тормышы белән кызыксына. Тимурчылар атна саен хәлен белешәләр, ярдәм итәргә тырышалар. Ул һәркемне кочак җәеп каршы ала, ихлас күңеленнән чыккан рәхмәтләрен үз телендә аңлата, дога кыла, тагын килүләрен көтеп кала.*

*Тирә-ягыбыздагы андый кешеләрне күңел җылысына тилмертмәсәк иде.*

*Равидә Фәхретдинова*

# Белә идегезме?

«Үзе бер карыш, сакалы биш карыш» дигән сүзләр әкиятләрдә безгә еш очрый. Күпме озынлыкта булган соң ул сакал? Яисә «Түтәрәм-түтәрәм тарым бар, күтәрә алсаң, барын да ал» дигән башваткычны кем генә белми? Бер түтәрәм тары күпме авырлыкта булган? Моны белү бик кызыклы бит. Күз күреме (тигез урында күреп була торган ара) – 3-4 чакрым. Өрмәк (эт өргән тавышны иштеп була торган ара) – 2-3 чакрым. Ук атымы (атылган укның очу ераклыгына тигез ара) – 0,6 чакрым. Колач – 1,7-1,8 м. Терсәк – 75 см. Адым – 70 см. Тотам (кул яссуы, дүрт илле) – 7,5-8,5 см. Бер илле (бармак юанлыгы) – 1,5 см. Сөям (кече карыш – имән һәм баш бармаклар арасы) – 16 см.Карыш ( имән һәм чәнчә бармаклар арасы) – 18 см. Пот – 16 кг. Батман – 4 пот чамасы. Кадак (гөрәңке) – 409,5 г чамасы. Мыскал – 1/96 кадак – 4,5 г чамасы.Түтәрәм – нәрсәнең булса да чиреге.Безнең бабайлар шулай ук чиләк, капчык, подаука, коштабак кебек үлчәү берәмлекләре дә кулланганнар.

# Кош оясы ясаганда

Аны агач такталардан да, бүрәнәдән дә (бүрәнәнең эчен чистартып) ясарга була. Фанералар куллану файдалы түгел, клей исен кошлар яратмый. Такталарны шомартмыйбыз – кошлар өчен шулай уңайлы. Сыерчык оясы артык зур булмаска тиеш. Зуррак ояга урнашкан сыерчыклар йомырканы күбрәк сала, нәтиҗәдә, бөтен балаларын да үстереп очырып бетерә алмаска мөмкиннәр.Кош ояларының «авызы»н зур итү дә дөрес түгел. Югыйсә, ояга песиләр һөҗүм итәргә мөмкин. Песи менмәсен өчен оя астына (агачка) тимерчыбыклардан ясалган боҗра беркетергә була. Зур авызлы кош ояларына еш кына тиеннәр дә оялый.Безнең ояга кошлар ояламый башлый икән, аны чистартырга вакыт дигән сүз. Кайнап чыккан су, яисә марганцовкалы су белән эшкәртүнең файдасы, һичшиксез, тиячәк.Кош оясын юлдан, сукмаклардан

## Якыннан танышыйк!



**Укучыларның сорауларына Фома урта гомуми белем мәктәбенең уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Хәйруллина Лилия Йосыф кызы җавап бирә.**

**- Лилия Йосыфовна, кечкенәдән хыялланган уй-теләкләрегез тормышка аштымы?**

-Әйе, барлык хыялларым да тормышка ашты.

**-Сез, бу дөньяда үзегезне бәхетле хис итәсезме?**

-Мин бик бәхетле.

**-Беренче икелегез хәтерегездә ничек уелып калды?**

-Икеле алганымны хәтерләмим. Өчле булгандыр, математикадан контроль эштән. «5» легә генә укып,”3”ле алгач уңайсызландым. Аны төзәтим әле дигәч, малайларның көлгәннәре хәтеремдә уелып калган. Мин ул өчлене төзәтеп, «4» ле алдым. Шушы хатирә онытылмый.

**- Сез укытучы һөнәрен сайлавыгызга үкенмисезме?**

- Юк, үкенмим, беркайчан да үкенгәнем булмады. Кечкенәдән өметләнгән хыялым ул минем.

**- Лилия Йосыфовна, сез мәктәптә җаваплы эш башкарасыз, сезнең эшегез гаилә тормышына комачауламыймы?**

-Юк, комачауламый. Алар шулай бер-берсенә үрелеп бара.

**-Бүгенге заман укытучысына алдынгы мәктәптә эшләве авыр түгелме?**

-Бик авыр. Укытучылар бүгенге көндә балалар өчен җаваплы булсалар, икенчедән, белем дәрәҗәсе өчен җавап торалар. Аларның хезмәте көннән-көн авырая бара. Бу һөнәр ияләренә баш иярга кирәк. Укытучы белемне бирә, ә дәүләт ул биргән белемне тикшерә. Бәяне дәүләт куя. Киләчәктә баланың язмышы аның нинди юлдан китүе, тәртипле булу-булмавы укытучыга да бәйле. Ул тиешле дәрәҗәдә тәрбия һәм белем бирә алырга тиеш. Югары дәрәҗәдә белем бирү өчен әти-әни, бала һәм укытучының бер үк юнәлештә эш алып баруы мөһим. Шул вакытта гына тиешле нәтиҗәгә ирешелә.

**— Газета укучыларыбызга теләкләрегез?**

-Газетага язучылар һәм аны укып нәтиҗә ясаучылар артсын.

- Без Сезнең белән әчтәлекле әңгәмә алып бардык, Зур рәхмәт.

**«Яшь журналистлар» түгәрәге әгъзалары**

## Экстремаль спорт төрләре

**Экстремаль спорт төрләре белән кызыксынучылар соңгы вакытларда шактый артты. Яшьләр дә, мондый “уен”нарның тормыш өчен куркыныч булуларын белә торып, әлеге спорт төрләре белән шөгыльләнүне хуп күрәләр.**

Күпсанлы акробатик элементлар, зур тизлек (биеклек, тирәнлек), адреналин – бәлки кешене нәкъ менә алар җәлеп итәдер? Теләсә нинди спорт төрендә сәламәтлеккә зыян китерә торган өлеше бар, диючеләр дә табылыр. Иң мөһиме шунысы истән чыгармаска: сакланып, тренер сүзен тыңлап, игътибар белән шөгыльләнергә кирәк.

**Сигвей полосы.** Атта утырып поло уйнау, күпләр фикеренчә, инде күптән искергән. Ничек кенә булмасын, бүгенге көндә дә әлеге спорт төре белән шөгыльләнүчеләр бар, тик менә атны гына сигвейга алыштырганнар! Әйтергә кирәк, моңарчы инде аны велосипедка утырып та, дөя, хәтта филләргә атланып та уйнаганнар.Сигвей дигән җайланма АКШта бик популяр. Apple компаниясенә нигез салучыларның берсе Стив Возняк та еш кына аның белән йөри. Сигвей үзенең уңайлы булуы белән җәлеп итә. Шуңа да полода ул тулысынча атны алтыштыра ала. Кагыйдәләр бераз үзгәртелсә дә, максат бер үк кала. Үз тәнең белән идарә итә белү, акробатик маневрлар ясауны таләп итә.

**Ат белән узышу.** Барысы да бер кешенең “мин йөгергәндә атны уза алам” дип мактануыннан башлана. Моны ишеткән Гордон Грин исемле фермер әлеге хикмәтле спорт төренә нигез салучыларның берсе була. Тәүге тапкыр 1980 елда оештырылган мондый ярышның максаты булып ат һәм кешенең 35 километрны калкулыклар аша узуы торган. Әлбәттә, ул чакта ат беренче килгән. кешеләр ат белән велосипедка утырып ярыша башлаган.

# Юл кагыйдәләре – безнең дусларыбыз!

26 нчы декабрь көнне мәктәбебезгә ЮХИДИ начальнигы Рөстәм Гарипов килде. Ул юл йөрү кагыйдәләре буенча җәяүлеләр транспорт юлын җәяүле юлы аша, урам чатларында исә тротуар линиясе буенча чыгарга тиешлеген кабат аңлатты, юлда машиналар агымы каршы якка булган очракта гына йөрергә һәм автомобильләр хәрәхәт иткәндә юл янында якын йөрмәскә киңәш итте. Җәяүлеләр көннең караңгы вакытында киемнәренә яктылыкны кире кайтара торган элементлар куйсалар үзләре өчен дә, башка юл хәрәкетендә катнашучылар өчен дә куркынычсыз булуын искәртте.



9 нчы декабрь көнне Нурлат шәһәренең 9 нчы мәктәбендә Россия дәүләт автоинспекциясенең 80 еллыгына багышлап “Яшь инспекторлар хәрәкәте» конкурсы булып үтте. Бәйгедә 24 команда, барлыгы 96 яшь инспектор катнашты. Конкурста безнең “Добрая дорога” командасы да уңышлы чыгыш ясады.



## Олимпиада — тырыш һәм сәләтлеләр бәйгесе






**Ниһаять, олимпиадаларның район турында җиңүчеләр дә билгеле булды:** Гумерова Ләйсән 7 класс, Сунгатуллина Рәзилә 5 класс математикадан призерлар. Гумерова Ләйсән 7 класс тормыш иминлеге нигезләре фәне призеры. Хисматов Рәсим 7 класс технологиядән җиңүче, Зиннуров Рәзил 10 класс, Гумеров Ранис 8 класс технологядән призерлар. Гайсина Гөлшат 9 класс химиядән җиңүче. Гумерова Ләйсән 7 класс, Гафурова Алия 10 класс татар теленнән җиңүчеләр.Тагиров Ильмир 4 класс татар теленнән призер. Зарипова Зилә 7 класс, Гафурова Алия татар әдәбиятыннан җиңүчеләр. Тагирова Гайшә 9 класс, Тагиров Габдеррәхим 5 класс татар теленнән призерлар.II артыеллыкта җиңүчеләр республикага район данын якларга барачаклар!

**Уңышларыгыз белән котлыйбыз, дуслар! Алдагы бәйгеләрдә дә сынатмассыз дип ышанып калабыз!**

# Хуш киләсең, Яңа ел!



Яңа ел бәйрәмнәре оешкан төстә һәркемнең күңеленә хуш килерлек итеп узды.Балалар аңа бик теләп әзерләнделәр. Башлангыч сыйныф укучылары озайтылган көн группасында тәрбиячеләре Галлямова Гөләсә апалары җитәкчелегендә матур итеп Кыш бабайлар ясадылар. 5-11 нче сыйныф укучылары газеталар чыгардылар. Гүзәл чыршыбызны 11 нче сыйныф укучылары бизәделәр.Тәрәзәгә тылсымлы бизәкләр төшерделәр.

Бәйрәмнәр 23 нче декабрьдән профсоюз чыршысы белән башланып китте. Ата-аналар бик актив булдылар, алар балаларының чыгышын тыңлап, уеннарда чын күңелдән катнашып, аларга зур таяныч булдылар. Барлык балалар да бик теләп, шатланып Яңа 2018 нче елны каршы алдылар. Кыш бабай белән



Кар кызы һәр бәйрәмгә яңадан—яңа уеннар, җыр—биюләр алып килделәр. Нурлат муниципаль районы башлыгы Равил Кузюров бүләкләренә барлык укучылар да чын күңелдән сөенде.

**Аглиуллин Аяз**

## УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ









Аглиуллина Әлинә фоторәсемнәре

VII РЕСПУБЛИКАНСКИЙ МОЛОДЕЖНЫЙ ФОРУМ
НАШ ТАТАРСТАН

«Безнең Татарстан» VII республика яшьләр форумына гаризалар кабул ителү дәвам итә, дип хәбәр итә Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте. Әлеге Форум – ел саен уздырыла торган төп яшьләр мәйданчыгы, анда һәр яшь кеше һәм аның командасы, үз проектын тәкъдим итеп, аны яклый ала.

Республика яшьләр форумы Татарстанда 2010 елдан бирле бара. Шул вакыт эчендә анда 7 меңнән артык кеше катнашып, 5500дән артык проект тәкъдим ителгән. Чараның максаты – яшьләрнең Татарстан Республикасын үстерүгә юнәлдерелгән

социаль әһәмиятле, инновацион һәм иҗтимагый-файдалы идеяларен һәм проектларын күрсәтү, алар буенча фикер алышу, аларны бәяләү һәм эшкә җигү өчен шартлар булдырудан гыйбарәт.

Быелгы катнашучылар форумның түбәндәге тугыз тематик мәйданчыгының берсенә үз проектын тәкъдим итә ала: «Кече Ватан территориясе», «Инновацияләр территориясе», «Архитектура һәм сәнгать территориясе», «Эшкуарлык территориясе», «Игелек территориясе», «Иминлек территориясе», «Спорт территориясе», «Тынычлык һәм татулык территориясе», «Яшьләр территориясе».

Теркәлү http://forumtatarstan.ru/ сайтында 2018 елның 20 февраленә кадәр барачак.

## Шигрияттә беренче адымнар

**Луна и звёзды**.

Вот за тучами она,
Пригляделася луна.
Светит ярко и светло,
Даже светится окно.
Каждой ночью удивляет,
Улыбается она.
И, конечно, подпевает .
Чтоб заснула детвора.
Появляются подружки
Озарные хохотушки
И смеются до утра,
Хотя давно  им спать пора.
И луна и звёзды
Дружат очень крепко.
Не страшны преграды
Лучшей дружбе этой.

**Аглетдинова Гулляр**

Декабрь аенда туучы кадерле укытучыларыбыз һәм техник хезмәткәрләребез:

**Хайруллина Лилия Йосыф кызы,**
**Гыйрфанова Ралия Наил кызы,**
**Әһлиуллина Гөлүсә Дамир кызы,**
**Хисматов Рамил Гариф улы!**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!

Декабрь аенда туучы укучыларыбыз:

Зиатдинов Эмиль, Щербаков Тимур, Мишин Ислам, Ахметова Назиля, Гумерова Ләйсән!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!



9 нчы декабрь –Ватан Геройлары көне

2007 елдан Россия Президенты Указы нигезендә

9 нчы декабрь Ватан Геройлары көне буларак билгеләп үтелә. Шул сәбәпле “Батырлык безнең янәшәдә» күргәзмәсе оештырылды.



Юнармеецлар тест эшлиләр

9 нчы декабрь көнне тарих фәненнән «Юнармеец-лар» Бөтенроссия онлайн-тест эшләделәр. Укучыларның 55% сорауларга дөрес җавап бирде.

## Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы


**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыймовна

**Урынбасары: Әһлиуллин Аяз**

**Дизайнер**: Гафурова Алия

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Аглетдинова Гөлләр, Закирова Гөлинә, Хисматова Зәринә, Хайруллина Әдилә, Гайнуллина Алия, Масгутова Гөлназ, Гайсина Вероника